**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

КАРАР

“01” октября 2019 ел №284

Төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә юллау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 3 августындагы 340-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына нигезләнеп, Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектлары шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килү-килмәве турында хәбәрнамә җибәрү (туры килмәү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов